РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР
СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2016 елның 28 июле № 25**

**Түбән Кама шәһәре халкына амбулатор-поликлиника ярдәмен күрсәтүнең нәтиҗәлелеген арттыру буенча эш эчтәлеге турында**

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча Сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе В.Р.Рәхимованың докладын, Түбән Кама шәһәр Советының Социаль сәясәт буенча даими комиссия рәисе Т.А.Куприянованың өстәмә докладын, Түбән Кама шәһәр Советының «Бердәм Россия» фракциясе җитәкчесе Н.Ф.Бухданованың Түбән Кама шәһәре халкына амбулатор-поликлиника ярдәмен күрсәтүнең нәтиҗәлелеген арттыру эшенең эчтәлеге турында чыгышын тыңлап һәм фикер алышып, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Үз компетенциясе кысаларында Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Сәламәтлек саклау идарәсенә (Рәхимова В.Р.) йөкләргә:

1.1. Түбән Кама муниципаль районы территориясендә Сәламәтлек саклауны алга таба үстерү максатларында 2016 елның 1 декабренә кадәр халыкка күрсәтелә торган амбулатор-поликлиника медицина ярдәменең сыйфатын һәм һәркем файдалана алырлык булуын арттыру буенча чаралар планын эшләргә һәм советка тапшырырга;

1.2. 2016-2030 елларга тармак үсешенең озак сроклы стратегиясен һәм Түбән Кама муниципаль районы территориясендә урта сроклы «Юл картасын» эшләү һәм тормышка ашыру буенча тулы чаралар күрергә;

1.3. балалар психиатрлары, педиатрлар, балалар неврологлары һәм белем бирү оешмалары педагоглары, социаль хезмәтләр эшендә дәвамчанлыкка аерым игътибар юнәлтеп, балаларга һәм үсмерләргә психиатрия ярдәме күрсәтүнең сыйфатын күтәрү буенча өстәмә чаралар күрергә;

2. Уңайлы сыйфатлы фтизиатрия ярдәме күрсәтүне оештыру максатларында Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына төзекләндерү эшләрен тәэмин итәргә тәкъдим итәргә:

2.1 туберкулезга каршы диспансердан Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсенең 1 нче сырхауханәсенә кадәр җәяүлеләр кичүе һәм Менделеев урамы буенча «Балалар шәһәр хастаханәсе» автобус тукталышына чыгуны кисеп

үтә торган җылылык трассасының вертикаль компенсаторын үтәү белән бәйләп оештырырга;

2.2 Мурадьян урамы буенча «Санаторий – профилакторий «Шифалы» трамвай тукталышына кадәр җәяүлеләр кичүе;

2.3 «Автомобилист» гараж кооперативы территориясеннән Менделеевск урамына турыдан-туры автотранспортны чыгару өчен юллар, дәвалау-профилактика профиле чикләнгән объект булган диспансер территориясе буйлап үтәли йөрүне төшереп калдырып, СанПиН таләпләренә туры китерергә тиеш.

3.Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча Сәламәтлек саклау идарәсенә тәкъдим итәргә (Рәхимова В. Р.):

3.1 амбулатор медицина ярдәменнән, шул исәптән табиб-белгечләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген арттыру буенча чаралар күрергә;

3.2 медицина эшчәнлегенә лицензиясе булган шәхси медицина учреждениеләре реестрын актуальләштерергә;

3.3 Түбән Кама территориясендә эшчәнлек алып баручы хосусый медицина учреждениеләре белән үзара хезмәттәшлек регламентын эшләргә;

3.4 өстәмә рәвештә хатын-кызларның сәламәтлеген саклау мәсьәләләрен өйрәнергә, 2017 елның 1 мартына кадәр сәламәтлек торышының төп индикаторларын яхшырту буенча чаралар эшләргә һәм хатын-кыз депутатлар төркеме тарафыннан башкарылган эш турында мәгълүмат тапшырырга;

3.5 барлык милек рәвешләрендәге дәвалау-профилактика учреждениеләре эшчәнлеген оештыруга ведомство контролен һәм оештыру-методик ярдәмнең һәм җитәкчелекнең дәрәҗәсен күтәрү буенча өстәмә чаралар күрергә;

3.6 куркынычсызлыкны, балаларга фтизиатрия ярдәме күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуын арттыру, оештыру мәсьәләләрен хәл итү максатларында , «Перинаталь үзәкле Балалар шәһәр хастаханәсе»ДАССОның 2нче номерлы сырхауханәсе базасында балалар фтизиатрының эшен тәэмин итәргә.

4.Дәүләт дәвалау-профилактика учреждениеләре, аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

4.1 регламент нигезендә шәһәр халкына профилактик медицина ярдәме күрсәтү өлешендә шәхси медицина учреждениеләре җитәкчеләре белән үзара хезмәттәшлекне оештырырга;

4.2 халыкка медицина хезмәте күрсәтүнең сыйфаты артыннан эчке контрольне, аерым игътибарны секторара хезмәттәшлеккә юнәлтеп, структуралаштырырга;

4.3 психосоматик авыруларны киметү максатларында учреждениегә медицина психологы вазыйфасын кертү мөмкинлеген карарга тәкъдим итәргә;

4.4 оешманың эшенә нигезләнгән шикаятьләр булдырмау, аларның физик, психик сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, озак еллар актив тормыш алып бару, медицина ярдәме күрсәтү шартларында шәһәрлеләрнең компетентлыгын арттыру максатыннан иҗтимагый оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре

белән хезмәттәшлек итү эшен көчәйтергә.

5. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә (Камелина М.В.) Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча Сәламәтлек саклау идарәсе белән берлектә (Рәхимова В. Р.):

5.1 массакүләм мәгълүмат чараларында халыкның физик һәм психик сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, озак еллар актив тормыш алып барган өчен шәхси җаваплылыкны арттыру мәсьәләләрен киң яктырту буенча уртак эшне көчәйтергә;

5.2 халыкка объектив һәм дөрес мәгълүмат җиткерү, шулай ук сәламәтлек саклау темасын яктырту белән шөгыльләнүче журналистларның компетентлыгын арттыру, алар өчен укыту семинарлары циклы үткәрергә;

6. Шәхси медицина учреждениеләре җитәкчеләренә киңәш итәргә:

6.1 Түбән Кама муниципаль районы халкына медицина ярдәме күрсәтү өлешендә дәүләт дәвалау-профилактика учреждениеләре белән хезмәттәшлекне оештырырга;

6.2 регламент нигезендә сәламәтлек саклау идарәсенең үз вакытында статистик хисаплылыгын тәэмин итәргә;

6.3 халыкка медицина хезмәтләрен күрсәтү сыйфатына эчке контрольне көчәйтергә;

6.4 медицина уку йортлары белән килешүләр буенча белгечләрне максатчан әзерләү шартларында югары һәм урта звено медицина хезмәткәрләренең үз кадрлар потенциалын формалаштыру буенча чаралар күрергә.

7.Түбән Кама муниципаль районы территориясендә эшләүче медицина иминият компанияләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

7.1 медицина учреждениеләре табиблары өчен даими рәвештә тематик укыту семинарлары үткәрергә;

7.2 физик һәм юридик затлар арасында ирекле медицина иминиятен үстерү буенча эшне дәвам итәргә

8. Түбән Кама шәһәр Советының «Бердәм Россия» фракциясенең хатын-кыз депутатлары берләшмәсенә халыкның сәламәтлеген, шул исәптән репродуктив сәламәтлекне саклау белән шөгыльләнүче субъектларның, гаиләләрнең социаль иминлеген тәэмин итү кысаларында үзара хезмәттәшлеген өйрәнүне йөкләргә.

9. Түбән Кама шәһәр Советының оештыру бүлегенә (Бикмөхәммәтова Л.М.) депутат берләшмәләре карарларын үтәүне контрольдә тоту системасын эшләргә һәм тормышка ашырырга.

10. Сайлау алды очрашулары нәтиҗәләреннән чыгып (РФ Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына) кабат Татарстан Республикасы Дәүләт Советына «Россия Федерациясендә туберкулезның таралуын кисәтү турында»2001 елның 18 июнендәге 77-ФЗ номерлы Федераль законны үтәмәгән өчен җаваплылыкны көчәйтү турында Россия Федерациясе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы белән чыгу тәкъдиме белән мөрәҗәгать итәргә.

11. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итәргә:

11.1 Түбән Кама шәһәрендә сәнәгать предприятиеләренең югары концентрациясен һәм бюджетларны формалаштырганда, халыкның сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга юнәлдерелгән федераль һәм региональ программаларны планлаштырганда һәм икътисадый нигезләгәндә халыкка зур техноген йөкләнешне исәпкә алып, матди-техник базаны ныгытуны, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган «Россия Федерациясе халкына медицина ярдәме күрсәтү тәртибе» нигезендә Түбән Кама муниципаль районының дәвалау-профилактика учреждениеләрен җиһазлауны тәэмин итүне күздә тотарга;

11.2 дәүләт медицина хезмәткәрләренең комплектлылыгын арттыру максатларында дәвалау-профилактика учреждениеләрендә табибларны беркетү өчен стимуллаштыручы чаралар һәм шартлар булдыруны үз эченә алган республика программасын гамәлгә ашырганда, Түбән Кама пропискасы булган медицина югары уку йортларын тәмамлаучыларга кызыксындыру чараларын тарату мөмкинлеген карарга кирәк.

12. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль сәясәт буенча даими комиссиягә (Куприянова Т.А.), Түбән Кама шәһәр Советының «Бердәм Россия» фракциясенә (Буханова Н.Ф.) йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р.Метшин